**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 июнь № 430

г. Казань

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесен, аңарга «Татарстан Республикасы юл хәрәкәте иминлеге фәнни һәм мәгариф программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт казна учреждениесен кушу юлы белән, үзгәртеп төзү турында

Татарстан Республикасында дәүләт сәясәтен камилләштерү һәм киләчәктә юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Россия Федерациясе Граждан кодексының 57 статьясы, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение), аңарга «Татарстан Республикасы юл хәрәкәте иминлеге фәнни һәм мәгариф программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Дирекция) кушу юлы белән, үзгәртеп төзергә, үзгәртеп төзелә торган Учреждение һәм Дирекция эшчәнлеге максатларын сакларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы исеменнән Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә ашыра;

Учреждение мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы гамәлгә ашыра;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә мөнәсәбәттә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына күрсәтелгән максатларга

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына:

Учреждениене, аңарга Дирекцияне кушу рәвешендә үзгәртеп төзү белән бәйле законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә үзгәртеп төзү чаралары нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

30 көн эчендә тиешле үзгәрешләрне кертергә:

үзгәртеп төзелә торган Учреждение һәм Дирекция эшчәнлеге максатларын саклау исәпкә алынган Учреждение Уставына;

Учреждениенең дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның 4 пунктын үтәү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күчемсез милек объектларына техник документларны тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

Дирекция эшчәнлеге туктатылу турында язуны юридик затларның бердәм дәүләт реестрына керткән көннән соң 30 көн эчендә элек Дирекциягә беркетелгән булган һәм Татарстан Республикасы милкендәге «Юл хәрәкәте иминлеге» ачык акционерлык җәмгыятенең 100 процент акцияләрен дәүләт мөлкәте белән оператив идарә итү хокукында Учреждениегә беркетергә;

әлеге пунктның икенче абзацы үтәлгән көннән соң 90 көн эчендә элек даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукында Дирекциядә булган җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукында Учреждениегә бирергә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертергә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә барлык үзгәртеп төзү чаралары тәмамланганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 10 декабрь, 933 нче карарына аны әлеге карар нигезләмәләренә яраштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 30 көн эчендә үзгәртеп төзелә торган Учреждение һәм Дирекция эшчәнлеге мәсьәләләре буенча норматив хокукый актларын әлеге карарга яраштырырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына тәкъдим итәргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков